| ГЛАВНОЕ<br>АРХИВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ<br>ПРИ КАБИНЕТЕ МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>(ТАТГЛАВАРХИВ) | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ<br>КАРШЫНДАГЫ<br>БАШ АРХИВ ИДАРӘСЕ<br>(ТАТБАШАРХИВ) |
|---|---|---|

11.12.2015 БОЕРЫК №089

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең 2015 елның 16 июлендәге 050 номерлы боерыгы белән расланган Архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру дәүләт функциясен башкару буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Физик һәм юридик затлар дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек иткәндә электрон документлардан файдалануны чикләүне гамәлдән чыгару өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә һәм Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм оешмаларда башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм алардан

файдалануны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 31 мартындагы 526 номерлы боерыгы чыгарылуга бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең 2015 елның 16 июлендәге 050 номерлы боерыгы белән расланган Архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру дәүләт функциясен үтәү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктта:

ундүртенче абзацны төшереп калдырырга;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының "Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм оешмаларда башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм алардан файдалануны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 31 мартындагы 526 номерлы боерыгы белән (алга таба - 2015 ел Кагыйдәләре) (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы http://wwww.pravo.gov.ru, 10.09.2015);";

унсигезенче абзацта «Росархив каршындагы ЦЭГЖ белән килештерелгән» сүзләрен «Росархив каршындагы ЦЭПК белән килештерелгән» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

1 нче таблицаның соңгы баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Мәҗбүри таләп билгели торган норматив хокукый акт |
|---|
| 125-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы;<br>2015 ел кагыйдәләренең 2 бүлеге;<br>ОСТ 55.6-85;<br>«Мәдәни кыйммәтләрне чыгару һәм кертү турында» 1993 елның 15 апрелендәге 4804-1 номерлы Федераль закон |
| 2015 ел Кагыйдәләренең 4 бүлеге;<br>Федераль башкарма хакимият органнарында эш башкару кагыйдәләре;<br>Россия Федерациясе Мәдәният һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының «Оешмаларның фәнни-техник һәм җитештерү эшчәнлегендә булдырыла торган типлаштырылган архив документларының саклау сроклары күрсәтелгән исемлеген раслау турында» 2007 елның 31 июлендәге 1182 номерлы боерыгы<br>558 номерлы боерык белән расланган исемлек |
| 2015 ел Кагыйдәләренең 4 бүлеге |
| 125-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьяндагы 3 өлеше, 23 статьясындагы1 өлеше, 17 статьясы;<br>2015 ел Кагыйдәләренең 2, 3, 5 бүлекләре |

| |
|---|
| 2015 ел Кагыйдәләренең 4, 5 бүлекләре; |
| 125-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясындагы 3 өлеше;<br>2015 ел Кагыйдәләренең 5 бүлеге |
| 125-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы;<br>2015 ел Кагыйдәләренең 6, 7 бүлекләре |
| 125-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы;<br>2007 ел Кагыйдәләренең 2 бүлеге |
| 125-ФЗ номерлы Федераль законның 4 бүлеге;<br>2007 ел Кагыйдәләренең 2, 3 бүлекләре |
| 125-ФЗ номерлы Федераль законның 6 бүлеге;<br>2007 ел кагыйдәләренең 5 бүлеге |
| 125-ФЗ номерлы Федераль законның 5 бүлеге<br>2007 ел Кагыйдәләренең 4 бүлеге |
| 63-ТРЗ номерлы Закон;<br>499 номерлы карар |

4 бүлектә:

2 нче таблицаның «Әлеге Регламентның 1.4 пунктында күрсәтелгән объектлар, муниципаль архивлардан тыш» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Тикшереп торыла торган объект төре | **Тикшерү үткәрү өчен тапшырыла торган документ** | **Документ формасын билгели торган норматив хокукый акт** |
|---|---|---|
| Муниципаль архивлардан тыш, әлеге Регламентның 1.4 пунктында күрсәтелгән объектлар | Төп исәп документларында һәр язмага түбәндәгеләр нигез була: | |
| | 1. Документлар оешма архивына кергәндә: | |
| | 1) даими, вакытлыча (10 елдан артык) саклана торган һәм шәхси состав буенча документларга структур бүлекчәләр описьлары, электрон делолар, документлар описьлары | 2015 ел Кагыйдәләре (23 нче, 24 нчекушымталар ) |
| | 2) башланган һәм тәгәлләнгән делолар саны турында рәсмиләштерелгән йомгак язма булган оешма делоларының җыелма номенклатурасы, структур бүлекчә делолары номенклатурасы | 2015 ел Кагыйдәләре (25 нче, 26 нчы кушымталар); |
| | 2. Документлар оешма архивыннан алынганда: | |
| | 1) акт архив документларын саклауга кабул итү-тапшыру | 2015 ел Кагыйдәләре (20 нче кушымта) |
| | 2) сакланырга тиеш булмаган архив актларын юкка чыгаруга аервп кую турында акт | 2015 ел Кагыйдәләре (21 нче кушымта); |

| | | |
|---|---|---|
| | 3) документларны югалту турында акт | 2015 ел Кагыйдәләре (6 нчы кушымта); |
| | 4) архив документларына төзәтеп булмаслык зыян килү турында акт | 2015 ел Кагыйдәләре (22 нче кушымта); |
| | 3. Архив эчендәге эшләрне башкару нәтиҗәләре буенча (шәхси документларның, архив коллекцияләренең җыелма описьларын, фәнни тасвирламаларын төзү, аеруча кыйммәтле делолар һәм документлар, иминият Фонды һәм куллану фонды описьларын төзү, берләштерелгән архив фондлары булдыру, документларның булу-булмавын һәм торышын тикшерү, исәпкә алу документларын чагыштырып тикшерү): | |
| | 1) даими, вакытлыча (10 елдан артык) саклана торган, шәхси состав буенча делоларның, шәхси делоларның җыелма описьлары | 2015 ел Кагыйдәләре (14, 15, 16, 17, 18 нче кушымталар); |
| | 2) даими саклана торган электрон делоларның, документларның описьлары, вакытлыча (10 елдан артык) саклана торган электрон делоларның описьлары | 2015 ел Кагыйдәләре (23 нче кушымта) |
| | 3) архив документларының булу-булмавын һәм торышын тикшерү акты | 2015 ел Кагыйдәләре (3 нче кушымта) |
| | 4) исәпкә алу документларында техник хаталар турында акт | 2015 ел Кагыйдәләре (4 нче кушымта) |
| | 5) документларны (әлеге фондка карамаган) документлар табылу турында акт | 2015 ел Кагыйдәләре (5 нче кушымта) |
| | 4. Стеллажлар буенча топографик күрсәткечләр карточкасы, фондның топографик күрсәткечләре карточкасы | 2015 ел Кагыйдәләре (1 нче, 2 нче кушымта); |
| | 5. Документлар керүне һәм аларның алынуын исәпкә алу кенәгәсе | 2015 ел Кагыйдәләре (11 нче кушымта); |
| | 6. Описьлар реестры | 2015 ел Кагыйдәләре (19 нчы кушымта) |
| | 7. Длоны таныклау бите | 2015 ел Кагыйдәләре (8 нче кушымта) |
| | 8. Дәүләт исәбе регламенты | 2015 ел Кагыйдәләре (29 нчы кушымта) |
| | 9. Фонд бите | 2015 ел Кагыйдәләре (12 нче кушымта); |
| | 10. Оешма архивы документларыннан файдалану: | |
| | 1) социаль-хокукый характердагы соратуларны үтәү: | |

| | | |
|---|---|---|
| | Архив белешмәсе | 2015 ел Кагыйдәләре (29 нчы кушымта) |
| | 2) Делоларны вакытлыча файдалануга бирү | |
| | 2.1) Делоларны вакытлыча файдалануга бирү турында акт | 2015 ел Кагыйдәләре (10 нчы кушымта) |
| | 2.2) Делоның алышма картасы | 2015 ел Кагыйдәләре (7 нче кушымта) |
| | 2.3) Документлардан файдалану кәгазе | 2015 ел Кагыйдәләре ( 9 нчы кушымта) |
| | 11. Норматив хокукый актлар: оешма нигезләмәсе яисә уставы; оешма структурасы һәм андагы үзгәрешләр; оешманың тарихи белешмәсе;<br>Эш башкару буенча аңлатма; эксперт комиссиясе төзү турында боерык, эксперт комиссиясе турында нигезләмә; архив турында нигезләмә, архив өчен җаваплы затны билгеләү турында боерык, архив өчен җаваплы затның вазыйфаи аңлатмасы; эш башкару өчен җаваплы затны билгеләү турында боерык, эш башкару өчен җаваплы затның вазыйфаи аңлатмасы; оешманы төзү, үзгәртеп кору һәм бетерү турында күрсәтмә актлар; архив җитәкчесе алышынганда кабул итү-тапшыру акты; | 2015 ел Кагыйдәләре. |

1.7.1 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән танышу турында, алар белән, шулай ук Татбашархив вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән килешүен яисә килешмәвен күрсәтергә. Тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә ачыкланган хокук бозуларны тикшерү актын алган датадан унбиш көн эчендә аларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта, Татбашархивка тикшерү актына һәм (яисә) ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәгә яки аның аерым нигезләмәләренә карата ризасызлыкны язма рәвештә тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат, индивидуаль эшкуар мондый ризасызлыкларга аларның нигезлелеген раслый торган документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен кушып бирергә, йә аларны дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына, муниципаль контроль органына килештерелгән вакытта тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелергә мөмкин;»;

5.1.4 пунктындагы 5 абзацта «электрон документлар рәвешендә» сүзләрен «көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документлар рәвешендә» сүзләренә алмаштырырга;

5.1.7 пунктындагы 8 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган зат тикшерү акты белән танышуы турында расписка бирергә яисә тикшерү акты белән танышудан баш тартуы турында расписка бирүдән баш тартса, акт Татбашархив делосында саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә беркетелә торган тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта хаты белән җибәрелә. Тикшерелә торган затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булганда, тикшерү акты әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта тикшерелә торган затка әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә күрсәтелгән документны алуны раслауны тәэмин итә торган ысул белән җибәрелгән акт тикшерелә торган зат тарафыннан алынган дип санала.»;

5.1.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле 15 абзац өстәргә:

"Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр, эксперизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алырга кирәк булган очракта, тикшерү акты контроль чаралары тәмамланганнан соң өч эш көненнән артмаган срокта төзелә һәм җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә расписка белән бирелә йә әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә тапшыру турында хәбәрнамә килә торган заказлы почта юлламасы белән (тикшерелә торган затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) яки муниципаль контроль кысаларында электрон рәвештә багланышлар алып баруга ризалыгы булганда) җибәрелә, күрсәтелгән документны алуны тәэмин итә. Шул ук вакытта күрсәтелгән документны тапшыру турында хәбәрнамә һәм (яисә) бүтән раслау Татбашархив делосында саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә беркетеп куела.».

Башлык И.Х.Әюпова